*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№7 (68)

Апрель-май, 2025 нче ел




**Бу санда**

*Тормыш юлы табышмакка тиңдер* 2

*Эзләнү юлында* 2

*Без - Тукайлы халык!* 3

*Без - театр күрсәттек!* 3

*12 нче апрель - Космонавтика көне* 4

*Халыкара балалар китабы көне* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Онытырга мөмкин түгел

*(Җиңүнең 80 еллыгын каршылап)*

Бөек Җиңүнең 80 еллыгы алдыннан гимназиядә төрле чаралар үтә. Укучылар “Җиңү тәрәзәләре” акциясендә теләп катнашып, сыйныф тәрәзәләрен бизәп куйдылар, 1 нче сыйныф укучылары Солдат боткасыннан авыз итте.

Бөтен ил буйлап «Хәтер бакчалары» чәчәк ата. Совет халкының батырлыгына рәхмәт һәм хөрмәт символы булган бу масштаблы халыкара акция бишенче тапкыр уздырыла. Бу акциягә кушылып, 9 нчы б сыйныфы укучылары, үзләренең әти-әниләре, сыйныф җитәкчеләре Ирина Тимерхановна белән берлектә гимназия территориясенә агачлар утырттылар.

29 һәм 30 апрель көннәрендә "Хорлар сугышы" үтте. Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган "Җиңү мае" декадасы кысаларында хәрби-патриотик җырлар конкурсы узды. Катнашучылар хорларны әзерләүләре һәм оештырулары белән таң калдырдылар.

Безнең ул дәһшәтле елларны онытырга хакыбыз юк!




### Мин - милләтемнең киләчәге, горурлыгы



30 апрель көнне Мөслим лицеенда «Мин - милләтемнең киләчәге, горурлыгы» дип аталган муниципаль конкурсының йомгаклау этабы узды. Әлеге конкурста 1 нче а сыйныфы укучысы Зиннуров Ильдан «Иң житез бала», 2 нче а сыйныф укучысы Шәйхәйдаров Илхан «Иң инсафлы бала» номинацияләрендә җиңү яуладылар. Җитәкчеләре: Гәлимарданова З.Д., Мортазина Л.Г.

### Экология айлыгы



Экология айлыгы кысаларында гимназиядә төрле дәрестән тыш чаралар үтә. Укучылар гимназия территориясен чүп-чарлардан чистарттылар.

1 апрель көнне 4 нче сыйныфларда һәм 1 нче б сыйныфында педагог-китапханәче Солтанова Г.М. Халыкара кошлар көненә багышланган “Канатлы дусларыбыз” исеме астында китапханә дәресе уткәрде. Балалар кошлар турында бик куп кызыклы мәгълүматлар белделәр, сорауларга җаваплар бирделәр.

9 нчы б сыйныфында Халыкара кошлар көненә багышланган экология дәресе үтте. Биология укытучысы Бариева Л.Ф. җитәкчелегендә "Экология көне: үзгәрешләргә илһам бир!» дигән чара да экология темасына багышланган иде. Чарада булганнан соң, һәркем әйләнә-тирә мохиткә үз йогынтысы турында уйланды дип ышанып калабыз.

# ТОРМЫШ ЮЛЫ ТАБЫШМАККА ТИҢДЕР

***Үз халкын данлаган татарлар: якташ галимә***

***Галиуллина Гөлшат Рәис кызы***

***Күренекле галимә, Казан федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле белеме кафедрасы мөдире***



Гөлшат Рәис кызы 1970 нче елның 5 нче ноябрендә Мөслим районы Югары Табын авылында туа. Сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1986-1989 нчы елларда Минзәлә педагогия көллиятендә белем ала. Югары белем алу максаты белән, һәр нәрсәне белергә, һәр күренешнең асылына төшенергә омтылып, Казан дәүләт университетының филология, та-рих һәм көнчыгыш телләре факультетына укырга килә. 1994 нче елда университетны кызыл дипломга тәмамлый һәм аспирантурага кала.

> ***Назлы һәм нәзакәтле ана, мәхәббәтле хатын һәм зур галимә! Көрәшчеләр рухы – аның канында…***
>
> ***Гөлфия Һадиева һәм Халисә Ширмән***

Филология фәннәре докторы, Казан университетының атказанган профессоры, күренекле тел галиме, ономаст, төрки дөньяга билгеле Гомәр Фәиз улы Саттаров җитәкчелегендә татар теленең антропонимик системасын – кеше исемнәренең кулланышын өйрәнә. 1999 нчы елда «ХХ йөз татар антропономиясе (кеше исемнәре мисалында)» дигән темага кандидатлык диссертациясе, ун елдан соң «Лингво-культурологик аспектта татар антропонимиясе» (2009) дигән темага докторлык диссертациясе яклый. 2008 нче елдан хәзерге татар теле кафедрасы мөдире, 2012 нче елда Казан федераль университетының хәзерге татар теле кафедрасы профессоры, 2015 нче елда татар теле белеме кафедрасы җитәкчесе, 2018 нче елда профессор гыйльми дәрәҗәсе бирелә. Гөлшат Рәис кызының үз алдына тегәл һәм ачык максат куеп, зур тырышлык белән эшләү нәтиҗәсендә ирешелгән казанышлары ул.

Гөлшат Галиуллина – иҗади фикерле, гаять максатчан эшләүче, фәндә тирәнлекне һәм төгәллекне ярата. Аның җитәкчелегендә өч фән кандидаты, биш магистрлык диссертациясе якланган.

















# ЭЗЛӘНҮ ЮЛЫНДА



Гөлшат Галиуллинаның әнисе - Фәһимә ханым

Проект эшләү барышында Гөлшат Галиуллинаның яшәгән йортын, әнисен күреп кайтырга уйлап укытучым белән Югары Табын авылына бардык. Әнисе Фәһимә апа белән очраштык. Ул безне якты йөз белән каршы алды.

Фәһимә апа Гөлшат Галиуллинаның балачагы, студент еллары турында хатирәләре белән уртаклашты.

Биш яшендә әлифбаны укып тәмамлаган була инде Гөлшат ханым. Ләкин ул вакытта укуга 7 яшьтән генә алалар. Бала вакытыннан ук белемгә омтылышы, үҗәтлеге, тырышлыгы көчле була. Шуңа күрә ул куйган максатларына ирешеп, бер-бер артлы югары үрләр яулый дигән, - нәтиҗәгә килдем якташым галимә Гөлшат Рәис кызы турында.

Фәһимә апаның кызы, оныгы Илһам өчен җан атып торучы күзләрендә чагыла. Гөлшат апаның төп нигезенә кайтуын сагынып көтәр кешесе бар. Шуңа күрә Фәһимә апага озын, хәерле гомерләр телибез. Кадерле кешесенең исән-сау булып кетеп торуына сөенеп Гөлшат ханым бик күп еллар әле туган нигезе сукмакларыннан атласын. Ана догасы барлык тормыш авырлыкларына киртә булып аны һәр җирдә озатып йөрсен.



Гөлшат Галиуллинаның туган нигезе

***Хәсәнова Йолдыз,***
***10 нчы сыйныф укучысы***

## БЕЗ - ТУКАЙЛЫ ХАЛЫК!




***26 апрель - Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан олысы-кечесе Тукай иҗатына мәдхия җырлый, аның шигырьләрен сөйли.***

***Шигырьдәгечә - Халык күңеленә ак нур сибүче, кара төннең якты ае, шаулы язның тургае булган Бөек Тукаебыз – мәңге безнең күңелләрдә...***

### Тукай бәйрәмендә гимназия укучылары

Тукай скверында, Мәллә авылында Тукай бәйрәме узды. Әлеге чарада гимназия укучылары да чыгыш ясады. "Калфак" вокаль триосы, Гәрәев Әминнең музыкаль чыгышлары, шигырь сөйләүче кызлар Ямалова Динә, Мөхсинова Динәнең сәнгатьле итеп сөйләүләре барлык катнашучыларны сокландырды. Ләйсән Әхмәтгаян кызы оештырган театр түгәрәгенә йөрүче 2 нче б сыйныфы укучыларының чыгышы да көчле алкышларга күмелде. Укучыларны музыка укытучысы Гөлнур Әзгамовна, туган тел укытучылары: Афзалова З.З., Мирзаморатова Г.М., Ямалова Г.Ф. әзерләде.









## БЕЗ ТЕАТР КҮРСӘТТЕК!

"Театр яктылыкка илтә" проекты кысаларында Мөслим гимназиясе укучылары Мөслим лицеенда Нәби Дәүлинең "Дуслар" пьесасыннан өзек күрсәттеләр.

21 апрель көнне Мөслим гимназиясенең 2 нче б сыйныфы укучылары, “Яшь театр сөючеләр” театр түгәрәгенә йөрүче балалар "Сәйяр" республика театр фестиваленең зона этабында районыбыз исеменнән чыгыш ясадылар. Жюри әгъзалары безнең артистларга искиткеч чыгышлары белән рәхмәт белдерде, шулай ук барлык башлангыч юлларында уңышлар теләде! Театр түгәрәге җитәкчесе Фәхертдинова Л.Ә.



# 12 НЧЕ АПРЕЛЬ - КОСМОНАВТИКА КӨНЕ

12 нче апрельдә без Космонавтика көнен билгеләп үтәбез. Космонавтика көне-барлык буыннарның яраткан бәйрәме. Беренче тапкыр аны нәкъ бер елдан соң — 1962 елның 12 апрелендә бәйрәм итәләр. 12 апрель көнне безнең гимназиядә Космонавтика көненә багышланган, 8-11 сыйныфлар өчен чара үтте.

Укучылар төрле тәҗрибәләр күрсәттеләр. Кунак булып лаеклы ялдагы физика укытучыбыз Сәяхова Зөлфирә Мөхәр кызы да килгән иде.



## Иксез-чиксез күк бит ул...

Ай елдан-ел Җирдән 4 сантиметрга ераклаша. 4,3 миллиарл ел эчендә ул 324 километрга ераклашкан. Беренче булып Ай тирәли очкан җәнлекләр – ташбакалар.

Юпитер – гигант планета. Кояш системасындагы барлык планеталар аның эченә сыя алыр иде. Юпитерның Ио дип исемләнгән иярченендә 400 вулкан барлыгы теркәлгән.

Венерадагы бер көн – бездәге 243 тәүлек. Ә бер ел 225 көн генә. Бу планета үз күчәре тирәсендә бик әкрен, ә кояш тирәли тиз әйләнә. Кояш системасында сәгать укларына каршы әйләнүче бердәнбер планета – Венера.

Плутон – кәрлә планета. Ул кояш системасындагы иң суык планета дип санала. Аның өсте боз белән капланган. Монда температура – 200 градуска кадәр төшә. Плутондагы боз без белә торган боздан күпкә аерыла. Ул корычтан берничә мәртәбә ныклырак икән. Плутондагы бер ел Җирдәге 248 елга тигез.



*Ә син беләсеңме?*

## ХАЛЫКАРА БАЛАЛАР КИТАБЫ КӨНЕ




2 нче апрельдә, бөек язучы-әкиятче Ганс Христиан Андерсенның туган көнендә, Халыкара балалар китабы көне билгеләп үтелә.

1967 елдан, ике елга бер тапкыр, әдипләрне һәм рәссам-иллюстраторларны Ганс Христиан Андерсен исемендәге халыкара премия белән бүләклиләр.

Татар язучылары арасында әлеге премиягә лаек булган язучылар – Шәүкәт Галиев (1982), Роберт Миңнуллин (1994), Рафаил Газизов (2006), Ленар Шәех (2022).

***

Китап – рухи хәзинә ул,
Укысын һәрбер бала,
Киңәшче дә, ярдәмче дә,
Дәреслеккә юл яра.

Тормышка дөрес юнәлеш
Бирә бары китаплар,
Киңәш бирә, ярдәм итә
Күп укысын балалар!

Укырга өйрәнә бала
Әлифба ярдәмендә,
Белемне арттырыр өчен
Укырга кирәк көн дә.

ТЫЛСЫМ+
Апрель, 2025 нче ел
№7 (68)
Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

Баш мөхәррир: Солтанова Г.М.
Техник редактор: Кадыйрова А.Р.
Мөхәррир: Замалова Зәринә
Корректорлар: Хәйруллина Диләрә
Корреспондентлар: Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
Дизайнер: Мостафина Рәйлә
Компьютерда җыючылар: Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә
Гамәлгә куючы: Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
Адрес: Мөслим, Кооператив урамы, 170а
Сайт: https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
Электрон адрес: tilsim2014@yandex.ru
Формат: А4 (А3)
Тираж: 100